**XI региональная научно-практическая конференция школьников**

**«Тукай укулары»**

# «Якташларыбыз иҗатында туган ягыбыз»

# «Родной край в творчестве наших земляков»

Выполнила:
Абдулова Мария, 8 класс
МБОУ “Сарсаз-Багряжская ООШ”
Заинского муниципального района
Республики Татарстан

Руководитель:
Чернова Ирина Григорьевна,
учитель татарского языка и
литературы

Заинск, 2021 г.

Эчтәлек.


I. Кереш. 3 – 4 бит.

II. Төп өлеш.

1. Якташларыбыз иҗатында туган як образы.

- Аяз Гыйләҗев 4 – 6 бит.
- Мөдәррис Әгъләмов 6 бит.
- Миргасыйм Әфләтунов 6 – 7 бит.
- Александр Кузьмин 7 – 8 бит.
- Флүн Разов 8 бит.

III. Йомгаклау. 9 бит.

IV. Кулланылган әдәбият. 10 бит.

## I. Кереш сүз.

Туган җир! Туган төбәк! Һәр кеше өчен нинди газиз, тирән мәгънәле сүзләр!

Мәктәптә әдәби туган якны өйрәнүнең максат-бурычлары, формалары, ысуллары күптөрле: якташ әдипләрнең тормыш һәм иҗатларын тикшерү, музейлар, әдәби почмаклар ачу, стендлар, альбомнар төзү, фольклор материалларын туплау һәм өйрәнү, истәлекле әйберләр, экспонатлар җыйнау, әдәби кичәләр, очрашулар үткәрү һ.б. Бу зур эштә аларга әдәби, тарихи чыганаклар, җирле һәм гомумән вакытлы матбугат, архив, музей материаллары, мемуар әдәбият, төрле хатлар, кулъязмалар, өйрәнелә торган әдипләрне якыннан белгән кешеләр дә һәм үзләре әдипләр дә ярдәмгә килә.

Зәйлеләр төбәктә туып үскән күренекле җәмәгать эшлеклеләре, әдәбият, сәнгать әһелләре белән хаклы рәвештә горурланалар. Кемнәр белән горурланабыз, матур мәгънәсендә кемнәр белән мактана алабыз соң без – Зәй кешеләре?

Әйе, Зәй төбәгендә туфрак бик тә уңдырышлы; анда шагыйрь дә, язучы да, галим - академиклар да, атаклы көрәшчеләр, спортчылар да үсә тора.

Әдәбият галиме, педагог, филология фәннәре докторы, Казан дәүләт университеты профессоры, Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе, «Фән һәм техника өлкәсендә Татарстан Республикасы Дәүләт бүләге лауреаты», «Халыкара ел кешесе» һ. б. - бу дәрәҗәләрнең һәм исемнәрнең барысы да бер үк затка - Хатыйп Миңнегуловка карый. Ул да Зәй төбәгенең Апач авылында туып үскән. Х.Миңнегуловның татар әдәбияты тарихы буенча язылган һәм бәһаләп бетергесез хезмәтләре бар.

Мөдәррис Әгъләмов, Рабит Батулла, Аяз Гыйләҗев, Флүн Разов, Иван Глухов, Александр Кузьмин шигырьләрендә һәм әсәрләрендә мәдхия җырлаган иксез-чиксез тугайлары-кырлары, урманнары, талгын гына агучы Зәй елгасы һәм Зәебезнең табигате искиткеч матур һәм кабатланмас.

Мин бу эшкә тотынганда үз алдыма түбәндәге бурычларны куйдым.

1. Үзебезнең якның шифалы суларын эчеп, сихәтле тау һавасын сулап үскән якташ язучыларыбызны, төбәгебезнең күренекле шәхесләрнең иҗатын тирәнтен өйрәнү.

2. Иҗади мирасларына күзәтү ясау.

**Эш планы:** фәнни хезмәт өч өлештән тора: кереш, төп һәм йомгаклау өлешләре.

Кереш өлештә Зәй төбәге, аның җирлегендә туып-үскән күренекле шәхесләре.

Төп өлештә якташ язучыларыбызның туган ягыбыз турында язылган әсәрләренә күзәтә ясау.

Йомгаклау өлешендә сүз якташ язучыларның иҗатлары халык күңеленә бик якын булуы һәм аларның әсәрләре аша без дөньяны ныграк аңлавыбыз турында ассызыклана.

**Нәтиҗә:** Зәй ягының күренекле вәкилләренең иҗади мирасын өйрәнеп, мин түбәндәгеләрне аңладым:

1. Зәй төбәге тарихи шәхесләргә бик бай.
2. Якташ язучыларыбызның иҗат мираслары гаять бай һәм күпкырлы.
3. Әдипләребезнең иҗатларын өйрәнүне дәвам итәргә кирәк.

**II. Төп өлеш.**

**1. Якташларыбыз иҗатында туган як образы.**

**- Аяз Гыйләҗев**

А. Гыйләҗев җырлы-моңлы, сихри Сарман ягында туса да, язмыш аны үзенең табигате, кешеләре үзенчәлекле, ярдәмчел, сабыр булган Зәй якларына алып килгән. А. Гыйләҗевләр гаиләләре белән Зәй районының Югары Баграж авылына күченеп, шунда яши башлыйлар. Бу вакытта Аяз агага ике яшьләр чамасы гына булса кирәк. Шушы Баграж авылы аның күңелен сабый чактан ук сихерли күрәсең.

Югары Баграж авылы табигатьнең иң матур сихри бер почмагына урнашкан. Ул замана сулышын тоеп яши. Авылны өч яктан гаскәр кебек агачлар урап, саклап тора. Урманы да аның бик бай. Моның шулай булуын А. Гыйләҗев та үзенең «Балачак сукмаклары» дигән язмасында матур итеп әйтеп

бирә. Болай дип яза ул: «Метери елгасы аръягында искиткеч матур, аллы-гөлле чәчәкләр капланган бәләкәй генә болын бар иде. Иртә яздан кара көзгәчә чәчәкләр бер-бер артлы ачылалар да җәйнең һәр аенда чәчәк исе була торган иде. Беркем кисәтмәсә дә, болынга аяк баскан кеше кинәт үзгәрә, чәчәкләрне өзмәскә, үләннәрне таптамаска тырыша. Кай яктан җилләр иссә дә, алар тыгыз һавалы бу үзәнгә төшеп җитә алмыйлар, көн туса без шул оҗмахта күбәләк җыябыз, качышлы уйныйбыз. Еш кына болынга эштән бушаганда әти дә төшә, безне түгәрәкләп тирә-ягына утырта, үләннәрнең исемен атап, берәм-берәм күрсәтә башлый. «Безнең якларда ашарга яраклы йөзләп үлән бар», - дия иде. Ниләр генә җыеп ашамый идек без Бagraж болын-урманнарыннан, җиләк-җимешне, гөмбәләрне әйтеп тә тормыйм, язга чыгып кар китүгә, кояшка караган ермак ярларына сап-сары булып бакыр тәңкәләр сибелә. Аланнарда кузгалак үсә, кыр какысы, урман какысы котырып уңа... Төрле якларга җир бәрәңгесе, карабаш, балтырган җыярга йөрибез», дип соклануын яшерми әдип.

Бу авыл кечкенә генә Баграж инешенә сыенган. Инеш аркылы матур итеп күпер салып куйганнар. Күперне чыгып бераз баргач, биек-биек «таулар» калкып тора. Тауларның хәтта исемнәре дә бар. Мәсәлән, «Дуңгыз сырты», «Сарык тавы». Тирән булмаса да елгалары да бар: «Метери елгасы», «Чүке елгасы», «Чуал елгасы»; чокырлары да бар: «Тирән чокыр», «Олы су башы». Чишмәләргә дә бай авыл ул- Югары Баграж. «Чүке» чишмәсе, «Такта чишмә», «Аракы» чишмәсе, «Кәҗә башы» чишмәсе. Бу чишмәләрнең күплеге авыл кешеләренең ярдәмчел, кунакчыл керәшен кешеләре, аларның тапкыр сүзле, зирәк кешеләр булуын күрсәтә кебек.

«Мин үзем күргән, тормышлары, яшәешләре, кылган гамәлләре белән мине баеткан бик күп кешеләр алдында зур бурычлы әле. Мин унҗиде яшемә хәтле авылда яшәдем. Сугыш еллары һәм аннан соңгы еллар иде бу. Шул елларның истәлеге минем өчен аерата газиз һәм кадерле. «Берәү», «Дүртәү» повестьларында мин бу истәлекләрнең бер өлешен язарга тырышып та карадым. 1972 елда «Язгы кәрваннар» һәм «Мәхәббәт һәм нәфрәт турында хикәят» исемле кечкенәрәк күләмдә ике повесть яздым. Бу минем үземнең

авылдашларыма, якты шәхесләргә, Югары Баграж кешеләренә, Зәй буйларына бурычымны кайтаруым гына. Әсәрләргә геройлар тормыштагы үз исемнәре белән кермәсәләр дә, географик һәм биографик дөреслеккә ябышып ятмасам да, бу әсәрләре минем янәшәмдә яшәгән гүзәл авылдашларым турында», - дип яза Аяз Гыйләҗев үзенең «Балачак сукмаклары» истәлекләрендә.

Хәзерге вакытта мәктәп музеенда якташ язучыларыбызга әдәби почмак булдырылган. Анда Аяз Гыйләҗев исеме күренекле урын алган. Урта Багражда әти-әнисе яшәгән йорт бүгенге көндә дә караулы, авылга якты истәлек булып тора.

**- Мөдәррис Әгъләмов**

Татарстанның халык шагыйре, Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе Мөдәррис абый Әгъләмовның һәрбер шигыре катлаулы, һәр юлында тирән сер, зур мәгънә яшеренгән. Ләкин бу беренче карашка гына шулай. Сер дигәнебез гап-гади сөю икән бит. Туган җирне, туган телне, әнкәңне, халкыңны, тормышны сөю. Ләкин ул шагыйрьнең кайнар күңеле аша үтеп, гайре табигый бер хискә әйләнә. Менә шушы хис шагыйрь белән укучы күңелен күренмәс җепләр белән тоташтыра. Үзең дә сизмәстән, шагыйрь торган биеклеккә менәргә омтыласың.

Аның шигырьләре һәм поэмалары  татар халкының рухи бөеклеген раслый. Туган җиргә, аның тарихына олуг мәхәббәт, киләчәгенә үткен караш, замандашларының эчке дөньясы белән кызыксыну – шагыйрь иҗатында төп урынны әнә шулар алып тора. М.Әгъләмовның «Шагыйрь авылда» дигән шигырен генә алсак та без анда шагыйрьнең туган ягына, авылына карата булган мәхәббәтен күрәбез, туган ягы шагыйрьнең иҗатына аһәң бирә.

Ә барыбер, туган җиргә кайттыммы,
Күкрәк тулып күтәрелә бер аһәң...
Этләре дә иҗекләп җыр яздыра,
Менә шул,
Сез дә ышанмассыз әле, сөйләсәм.

(«Шагыйрь авылда»)

**- Миргасыйм Әфләтунов**

Миргасыйм Әфләтунов әсәрләре тема һәм жанр ягыннан бик бай. Аның шигъри тәлгәшләрендә, проза әсәрләрендә дөнья матурлыгы, якыннарына мәхәббәт, туган ягыбызга, тарихыбызга, телебезгә чиксез хөрмәт чагыла. Аның лирикасында туган як темасы әйдәп баручы темаларның берсе булып тора.

Миргасыйм Әфләтуновның «Гөрләп үсәсең, Зәем» шигыре матур Зәй төбәгенә багышланган. Лирик герой өчен туган як яме тормыштагы һәрнәрсәдән өстен. Аның туып-үскән ягы «гөрләп үсә», «таңнары алсу», «утлары балкып яна». Гипербола - арттыру , сынландыру алымнары аша лирик геройның соклану хисе үстерелә. Шигырьнең беренче строфасы болай яңгырый:

Зәйдә тудым, шунда үстем,
Иңләп йөздем суларын.
Читтә булсам, сагынып кайтам,
Гел уң була юлларым.

Автор соңгы строфада үзенең укучыларына теләген җиткерә. Туган якта яшәргә кирәклеген әйтә:

Яшә туган төбәгеңдә,
Туган җиргә ни җитә!
Ал булса да, гөл булса да,
Бәхет эзләмә читтә.

Шагыйрь шулкадәр җылы итеп, сокланып үз туган ягы турында гына яза ала.

**- Александр Кузьмин**

А.Кузьмин үз шигырендә балачактан күңелендә калган хатирәләрен яңартып, инде олыгайгач, уйландырган уйларын да язган. Аның әсәрләренә авторның йөрәге аша үтеп, шигырь юлларына әверелгән кичерешләр дәрьясы, уйланулар сыйган. Аның әсәрләре аша һәркем туган якның ниндидер серле тарту көчен, сихри романтикасын тоя, шул хиснең чынлыгына, кеше өчен кадерле булуына ышана:

Синдә генә бит ул саф чишмәләр,

Синдә генә бит ул тау ягы.

Синдә генә еракларда калган

Ямьле яшьлек илем – Багражым.

Җырчы кошларыңны тыңлый-тыңлый,

Үтте балачагым, яшь чагым.

Нинди генә хәлдә булсаң да син,

Сиңа кайтам, сиңа, Багражым!

(«Туган авылым – Багражым»)

Туган якның агым сулары кебек лирик героебызның йөрәге ярсу, туган як таңнары кебек үк аның йөзе алсу. Кыскасы, яшьлеккә хас тойгылар бәрелешеп, ташкын хисләр өермәсен – туган як шигырьләренең һәр сулышында тоеп торабыз. Ул үз авылын, яшьлеге үткән Багражын сагынып, туган ягына кайта.

**- Флүн Разов**

Туган як! Туган җир! Туган авыл! Аның матурлыгына кем генә сокланмаган да, ул турыда кем генә шигырьләр язмаган! Авторның «Бар», «Сорасалар», «Дуслык каласы», «Сокланамын», «Таңнар ата алсуланып”, «Мин туганмын арыш басуында... », «Юлга чыктым исә... », «Туган ягым» һәм башка бик күп шигырьләре туган ягына, туган халкына, туган ягының табигатенә чиксез мәхәббәт, горурлык хисләре белән сугарылган.

Ашар өчен – ашым,

Сулар өчен – һавам,

Мул табынлы җылы өем бар!

Дошман – көнләшерлек,

Дуслар – сөенерлек,

Татарстан дигән илем бар! («Бар» шигыреннән)

Мин туганмын

Арыш басуында,

Көлтәләре булган бишегем...

Бу тормышка шуннан аяк бастым,

Киереп ачып аның ишеген.

Шуңа күрә

Минем тәннәремә

Сеңеп калган арыш исләре,

Шунда туган җиргә мәхәббәтем,

Йөрәгемдә сөю хисләре. («Мин туганмын арыш басуында... »)

**III. Йомгаклау.**

Матур әдәбиятка йөкләнгән төп бурыч – матурлыкны тасвирлап күрсәтү. Матурлыкның башкалар абайламаган якларын күрү өчен бер күз – күңел күзе кирәк. Без әдәби әсәр белән танышканда анда тасвирланган матурлыкка хәйран калабыз. Ә матурлык үзе тагын бер матурлык тудыра. Табигатьнең матурлыгына сокланабыз! Әле ничек кенә сокланабыз! Ә мондый әсәрләр озак яшиләр, яшәрәләр.

Туган җиренең туфрагын, үз халкының күкрәк җылысын йөрәге аша тоймаган әдип кеше йөрәгенә үтеп керә алмый. Язучыларыбызның әсәрләре аша без үз төбәгебезне яратырга, аның кешеләре белән горурланырга өйрәнәбез. Якташларыбызның матур сыйфатларын үзебездә булдырырга омтылабыз.

Фәнни-тикшеренү эшемне зур кызыксыну белән башкарып чыктым. Зәйдән күпме данлыклы, күренекле кешеләр чыккан, күбесе әле хәзердә үзләренең иҗат баскычлары буенча өскә күтәреләләр. Язучыларыбыз һәм шагыйрьләребез дөньяны танып-белергә, андагы яхшы һәм начарны аера белергә генә түгел, туган ягыбызның байлыгын, матурлыгын күрергә дә, музыкасын, шигъри нәфислеген тоярга да өйрәтәләр.

Татарстанга күренекле җырчылар, язучылар, шагыйрьләр, сәнгать, мәдәният, дәүләт эшлеклеләре, Хезмәт алдынгылары биргән Зәй ягы бүген дә тулы канлы тормыш белән яши. Безнең халык һәрчак белемгә, яктылыкка омтылган, киләчәк буынны да шул рухта тәрбияләгән. Тирә-ягыбызда милли рухлы кешеләр булганда, уңдырышлы Зәй ягыннан әле байтак талант ияләре чыгар.

**IV. Кулланылган әдәбият.**

1.Әхмәтҗанов Р.Г., Глухов И.Г. Тарихта калган эзләр. – Зәй район типографиясе, 2008

2. Гыйләҗев А.М. Балачак сукмаклары //Зәй офыклары, 24 январь, 1998.- Б. 5.

3. Гыйләҗев И.А. Истәлекләр. – Казан: Татарстан китап нәшр., 2006.- 71-75 б.

4. Даутов Р.Н. Балачак әдипләре. – Казан: «Мәгариф» нәшр., 2002.- 78-86 б.

5. Төбәгем тургае. Шигырьләр, хикәяләр. – Зәй шәһәре, 1997 ел.

6. Туган як авазы. «Зәй энҗеләре» әдәби берләшмәсенең эш тәҗрибәсеннән. Зәй шәһәре, 1990 ел.